*Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр. Аның шигырьләре буыннан-буынга калып, миллионнарча балаларыбыз тарафыннан ятланачак вә аның шанлы исеме мәңгегә онытылмаячак.*

Габдрахман Кәрам

*Тукай для нас – это колыбельная песня, это – чудо первых слов. Это – чудо поэтического гения, это и взгляды, и воспитание.*

Михаил Львов

*Его поэзия всегда современна и актуальна. Взяв любое стихотворение Тукая, чувствуешь, как будто оно написано сегодня.*

Габдулла Арипов

Габдулла Тукай
Бәхетле бала
Счастливый ребенок

*Балалар өчен шигырьләр, поэмалар, автобиографик повесть, мәсәлләр*
*Стихи, поэмы, автобиографическая повесть, басни для детей*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2011

КАЗАНЬ • ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • 2011

УДК 821.512.145-1-93+34
ББК 84(2Рос=Тат)-5+7
Т72

Төзүче-мөхәррире *Гөлнара Сибгатова*

Редактор-составитель *Гульнара Сибгатова*

**Тукай, Г.М.**

Бәхетле бала : балалар өчен шигырьләр, поэмалар, автобиографик повесть, мәсәлләр = Счастливый ребёнок : стихи, поэмы, автобиографическая повесть, басни для детей / Габдулла Тукай; төз. Г.Сибгатова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 216 б.
ISBN 978-5-298-02015-2

Әлеге китапка татар әдәбиятының классик шагыйре Габдулла Тукайның балалар өчен язылган шигырьләре, поэмалары, автобиографик повесте, мәсәлләре һәм аларның рус теленә тәрҗемәләре туплап бирелде.

В эту книгу вошли стихи, поэмы, автобиографическая повесть, басни поэта-классика татарской литературы Габдуллы Тукая и их переводы на русский язык.

УДК 821.512.145-1-93+34
ББК 84(2Рос=Тат)-5+7

ISBN 978-5-298-02015-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Сибгатова Г.Ф., төзү, 2011

## ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ

Габдулла Тукай (Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев) 1886 елның 26 апрелендә Татарстан Республикасының Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Габдуллага алты ай булганда – әтисе, өч яшендә әнисе дөнья куя. Шул көннән нәни Апуш кулдан-кулга йөртелә башлый. Башта Өчиле авылына – бабасының ишле гаиләсенә барып эләгә. Әмма гаиләгә артык тамак булып килеп кергән малайдан бик тиз котылырга телиләр һәм, ямщикка утыртып, Казанга озаталар. Анда ике ел яшәгәннән соң, үги әтисе һәм үги әнисе авырып китү сәбәпле, кечкенә Габдулланы Өчилегә кайтаралар. Аны Кырлай авылында яшәүче Сәгъди абзый гаиләсе уллыкка ала. Тик монда да малайга озак яшәргә насыйп булмый. Бу юлы аны Җаек (Уральск) шәһәрендә яшәүче туганнары үзләренә соратып алалар. Монда Габдулла «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә һәм аның каршындагы рус классында укый. Татар халык иҗатын һәм язма әдәбиятын җентекләп өйрәнә. Гарәп, фарсы, төрек, рус һәм Көнбатыш әдәбияты белән таныша. «Фикер» газетасын, «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр») һәм «Уклар» журналларын чыгаруда катнаша. Үзе дә шигырьләр яза башлый.

1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. «Әлислах» газетасын, «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын чыгаруга зур өлеш кертә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр рухланып иҗат итә. Хәтта Казанның Клячкин больницасында үлем түшәгендә ятканда да шигырьләр яза, туган халкына хезмәт итә.

Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була, Яңа бистә зиратында җирләнә.

Тукайның кыска гына гомерендә иҗат ителгән олы мирасының яртысын диярлек балалар шигырьләре алып тора. Үзе исән чакта дөнья күргән 34 китабының 16 сы балаларга багышлана.

1958 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе булдырыла.

Бүгенге көндә Арча районының Яңа Кырлай авылында – Габдулла Тукай музей-комплексы, шул ук районның Кушлавыч авылында – Тукаевлар музей-йорты, Казанда Габдулла Тукай әдәби музее эшли.

## БИОГРАФИЯ

Габдулла Тукай (Габдулла Мухамметгарифович Тукаев) родился 26 апреля 1886 года в деревне Кушлавыч Арского района Республики Татарстан в семье муллы. Когда Габдулле было шесть месяцев, у него умер отец, в трёхлетнем возрасте – мать. С этого дня маленький Апуш переходил из одной семьи в другую. Сначала он попал в деревню Училе в многодетную семью деда. Но от мальчика, который здесь был лишним ртом, хотели избавиться и с ямщиком отправили в Казань. Там он прожил два года и, когда его приёмные родители заболели, маленький Габдулла вновь вернулся в Училе. Его взяла на воспитание семья Сагди абзый из Кырлая. Но и здесь мальчик прожил не долго. В этот раз его забрали родственники из Уральска. Здесь Габдулла учился в медресе «Мутыйгия» и русских классах при ней. Тщательно изучил татарский фольклор и письменную литературу. Познакомился с арабской, персидской, турецкой, русской и западной литературой. Участвовал в выпуске газеты «Фикер» («Мысль»), журналов «Эль-гаср-эль-джадид» («Новый век») и «Уклар» («Стрелы»). И сам начал писать стихи.

Осенью 1907 года Тукай вернулся в Казань. Внёс большой вклад в выпуск газеты «Эль-ислах» («Реформа») и журналов «Яшен» («Молния»), «Ялт-юлт» («Зарница»). До последних дней своей жизни он вдохновенно творил. Даже при смерти, когда лежал в Клячкинской больнице Казани, писал стихи, служил родному народу.

Габдулла Тукай скончался от болезни лёгких 15 апреля 1913 года в Казани, был похоронен на кладбище Новотатарской слободы.

Прожив короткую жизнь, Тукай оставил огромное наследие, почти половину которого занимает детская литература. При жизни поэта были изданы 34 книги, 16 из которых посвящены детям.

В 1958 году была учреждена Государственная премия Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая.

Сегодня работают музей-комплекс Габдуллы Тукая в деревне Новый Кырлай Арского района, дом-музей Тукаевых в деревне Кушлавыч того же района, литературный музей Габдуллы Тукая в Казани.

# ШИГЫРЬЛӘР
# СТИХИ

## ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл[1], дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

## ТУГАН АВЫЛ

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән...

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлебез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер: кая ташлар бу тәкъдирем[1];
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

**БАЛА БЕЛӘН КҮБӘЛӘК**

Бала:
Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып,
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:
Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын,
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, –
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

**ФАТЫЙМА БЕЛӘН САНДУГАЧ**

Фатыйма:
Ни өчен син сайрамыйсың, Сандугач?
Шат була күңлем минем, син сайрагач.
Читлегең әйбәт, яныңда бар ашың:
Ник күңелсез син болай, бөктең башың?

Сандугач:
Аһ, минем сайрар җирем урман иде,
Анда һәртөрле кызык тулган иде.
Мин бу җирдә нигә шатлык күрсәтим?
Анда өч баш кошчыгым калды ятим!

Һәм мине анда тагын дустым көтә,
Сагына ул, саргая ул, ут йота.
Белмисеңме син: читен мәхбүслек[1] ул,
Булса да алтын, һаман да читлек ул.

Фатыйма:
Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа:
Бар, азат бул, кыл миңа изге дога.
Бар, җаным, инде яшел урманга оч,
Тиз ятим кошчыкларың берлән кавыш.

**КАРЛЫГАЧ**

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
Оя итте минем сөйгән карлыгачым.

Ул көн буе аузы берлән балчык ташый,
Балчык берлән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара

Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

Карлыгачым ямьсез озын кара төндә
Каты йоклый оясында, алмый тын да;

Бер канатының астына тыга башын,
Уянмый ул, – бөтен кеше тавышласын,

Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр килсен яшен,
Төн буена нинди каты җил исмәсен,

Ни булса да бары да бер аның өчен, –
Уянмый ул, селкетми дә борын очын.

**ШАЯН ПЕСИ**

Күрче, бик чынлап керешкән эшкә безнең Ламига,
Бар уе – бер бик матур күлмәк тегү курчагына.

«Күлмәгем кайчан бетәр?» – дип, курчагы яткан, көтә;
Көтми хәл юк, бер тәти күлмәк кирәк, – бәйрәм җитә.

Ә песи яшьрен генә яткан, кәтүкне күзлидер;
«Тукта, селкенмәсме», – ди ул; бер дә җаны түзмидер.

Ул хәзер сикрер менә, хәзер тотар, хәзер басар;
Ул кәтүкне уйнатыр, уйнар, үзенә шар ясар.

Кайгысы юк ул песинең, тик һаман уйнау уе;
Бик шаян! Ай-һай, наян! Уйнарга хәзер көн буе!

**ЭШ**

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән эшләргә көн;
Эшләп аргачтын бирелгәндер тыныч йокларга төн.

Иртә торгач та язарга, дәрсең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн.

Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буе яктыра.

Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.

Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң[1] һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың берзаман!

**ЭШ БЕТКӘЧ, УЙНАРГА ЯРЫЙ**

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәге дәрсен карый.

Чын күңел берлән укый ул, кат-кат әйтеп һәр сүзен;
Бик озак шунда утырды, бер дә алмастан күзен.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, – ди, – әйдә тышка, ташла дәрсең, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман;
Чыкчы тышка, нинди якты, нинди шәп уйнар заман!»

Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабыр ит, уйнамыйм, – ди, – уйнасам, дәрсем кала.

Көн озын ич, ул уенның мин һаман вактын табам,
Чыкмамын тышка уенга, булмыйча дәрсем тәмам».

Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә.

Өй түренә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман,

Чыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп уйнар заман!»

Сандугачка каршыга биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәрсем кала.

Туктале, бетсен дәрес, – ди, – әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!»

Ул, шулай дип, һич зарар бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап кереште дәрсенә.

Шулвакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңлең ач;

Бик күңелсездер сиңа эштә утырмак һәрвакыт,
Әйдә, чык син бакчага, җитте хәзер уйнар вакыт!»

Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәрсем кала.

Тукта, сабрит[1] аз гына, – ди, – и кадерле Алмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач».

Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәрсене,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны – барсыны.

Чыкты йөгреп бакчага:
«Йә, кем чакырды, – дип, – мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәрсеми».

Шунда аңар бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңар кып-кызыл зур алма бирде Алмагач;

Шунда аңар шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңар баш иделәр бакчада һәрбер агач.

## БӘХЕТЛЕ БАЛА

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканны белсә.

Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас – менә бәхте аның шунда.

Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә.

## БӘЙРӘМ БҮГЕН

Бар күңеллек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген!
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкаддәс[1] хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын:
«Ул киенгәндер!» – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
«Ислемай сөрткән икән дөнья!» – дидем: бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
«Күңле нечкәргән!» – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын;
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

## КЫШКЫ КИЧ

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, тезелешеп, –
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми һич тә.

Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә,
Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә.

Тышта иссен ачы җилләр, тузсын карлар,
Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,
Суыклыктан очар кошлар очалмасын, –
Сезнең урын җылы, әйбәт, – ни кайгы бар?

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:
Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;
Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,
Ата-ана вафат, җирсез һәм йортсызлар.

Мондый кышкы кичтә сыгныр[1] урыннары
Аларның юк, өши бите, борыннары;
Үлми калса яхшы алар салкынлыктан,
Кайберсенең шуннан була үлемнәре.

Очрый калса сезгә шушындый ярлылар,
Яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар, –
Яшь балалар! аларны сез яратыгыз,
Җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

## ЯЛКАУ МАЭМАЙ

Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә,
Җитезләнә, уйный һаман йөгрә-өрә;
Карый миңа мәхәббәтле күзе белән,
Гүя «уйныйк» дигән була, гүя көлә.

Кайвакыт ул ята тәмле ашап туеп,
Ал аяклары өстенә башын куеп.
Аны шунда чебен халкы тынычсызлый;
Ялкау маэмай! Ул аларны тормый куып.

Чебеннәрне астан гына карап ята,
Ярты йомык күзен генә ялтырата;
Бервакыт ул колак артын торып кашый,
Чебен халкы шунда тиз-тиз кача башлый.

**БИЧАРА КУЯН**

– И Куян, куркак Куян, йомшак Куян,
Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан?

– И җаным, син яшь бала шул, белмисең;
Төште зур хәсрәт, ничек моңланмыйсың.

Без икәү: Әткә куян, Әнкә куян,
Яшь куянчыклар янә бездән туган.

Барчабыз бер гаилә булган идек,
Күп заман шатлык белән торган идек.

Яшь балаларны ашап китте бүре,
Бик усал ерткычтыр ул, муркыргыры!

Күп тә үтми куйды дөнья әнкәсе;
Тулды күңлем, ничек итеп әйтәсе:

Килде дә бер явыз аучы эт белән,
Атты үтерде аны мылтык белән.

Шул вакыттан бирле аш булмый ашым,
Моңланам ялгыз башым, агызам яшем.

**КЫЗЫКЛЫ ШӘКЕРТ**

– Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

– Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, –
зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!

**САБИТНЫҢ УКЫРГА ӨЙРӘНҮЕ**

Сабит алты яшендә, инде гакълы башында;
Ялгыз, иркә бала ул әткәләре кашында[1].

Шуңар күрә шаян ул, бик күп уйный, наян ул;
Күңеллелек, көлкеләр таба әллә каян ул.

Фәһме[2] үткен, ул зирәк, андый балалар сирәк;
Һәрбер әйберне сорый ул: бу ни нәрсә?
Ник кирәк?

Сабит сорый җентекләп, һәр нәрсәне бөртекләп,
Әти белән әнисе җавап бирә бик ипләп.

Беркөн Сабит әткәсен күреп әйтә әйтәсен:
«Әти, миңа әлепби[3] кайчан алып кайтасың?

Мине укырга өйрәт, миңа укырга кирәк;
Үзем укыйм мин китап, үзем сөйлим һәм көйләп».

Атасы хәйран булды, китапчыга йөгерде,
«Бүләк» атлы әлифба алып кайтты ул берне.

«Бер адым, – дип, – гыйлемгә», өйрәтә ул Сабитка;

Салган Сабит ихласын, кош бәбкәседәй җимгә.

Монсы – «әлиф», монсы – «ба», бу хәреф – «җим»,
монсы – «та»,
Бусы «дал» хәрфе була, бу хәреф – «зат»,
монсы – «та».

Салган Сабит муенны, оныткан ул уенны;
Тырышып укый «Бүләк»не, белми көнне һәм төнне.

Әткәй алган китапны тапты Сабит бик татлы;
Тиздән белде бик яхшы: нинди хәреф ни атлы.

Беркөн чәй эчкән вакыт укый Сабит шартлатып;
Әти белән әнисе торышалар шаккатып.

Укуы өзек аның – балачарак баланың:
«Бу ә-лиф-ба – бүләге Харитонов бабаның».

Хәйран булды әнкәсе, гыйлем булгач бәбкәсе;
Чәй катында елмая куанычлы әткәсе.

Күрсәң иде әнкәсен: кочып алган бәбкәсен,
Үбә-үбә бихисап битен, күзен һәм кашын.

## МӘКТӘПТӘ

Менә көз барча кырларны вә урманны ялангачлый,
Менә ак тун киеп инде күңелсез кыш килә башлый.

Игеннәр тулган ындырга, халыкның эшләре беткән,
Вә көньякның вакытча безгә килгән кошлары киткән.

Урамнарда күңелсезлек, авылда сизлә бер кайгы,
Терелекләр вә шау-шулар, кызыклар кайда ул җәйге!

Күңелсез һәм дә ямьсез булса да шулчак табигатьтә,
Кызык ләкин, күңелле бик авыл кырыенда мәктәптә!

Укулар кычкырып анда! бөтен мәктәп килә шау-шу!
Кызык җәй айрылып торган укуга көз көне каушу!

**АЙ ҺӘМ КОЯШ**

Һималая тау өстендә алтын бишек,
Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп;
Җил төн буе йоклаганын саклап тора,
Тирбәтә һәм өстен, башын каплап тора.

Йокысыннан Кояш ничек уяндисә[1],
Җил шулвакыт җилбер-җилбер итеп исә;
Исә-исә бөтен дөнья буе китә:
«Торыгыз! – ди. – Уянырга вакыт җитә!»

Торып чыккач шул бишектән Кояш агай,
Анда кереп йоклый инде энесе Ай;
Йоклый шунда йолдызлар да, өелешеп,
Оядагы йоклап яткан кошчыклардай.

Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә[2],
Торып чыга, көлеп, җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне –
Менә шулай дуслык белән нәүбәтләшә[3].

**КОШЛАРГА**

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңлегезгә Тәңре нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим сезгә, тимим;
Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!

Курыкмагыз – яхшы белән, мин һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.

## АК БАБАЙ

Бөтен дөнья аппак булып, кар яуганда,
Ишегалды, урам, түбә агарганда,
Аппак булып кайтып килә безнең бабай,
Безгә төрле-төрле уенчык алган да.

Шатланышып, без әйтәбез: «Рәхмәт, бабай,
Сиңа тагын күп ел гомер бирсен Ходай!»
Бабай, мескен, кар, яңгырга карамыйча,
Безне шатландырмак өчен йөри шулай.

## ГАЛИ БЕЛӘН КӘҖӘ

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

## ҺӘР ЯЛТЫРАГАН АЛТЫН ТҮГЕЛ

Төнлә берлән бакчада бер аллы-гөлле күбәләк,
Очкалап йөргәндә уйнап, анда-монда чүгәләп,

Күрде кырда: бик матур бер әллә нәрсә ялтырый,
Нурлана, җем-җем итә йолдыз шикелле, калтырый.

Күбәләкнең бер дә чик юк һәр матурга гыйшкына:
Тиз генә ул барды да кунды матур зат өстенә.

Ул матур зат – юлчылардан сүнми калган ут иде:
Күбәләк булды һәлак, шунда кунып: янды, көйде.

## ЯҢГЫР ИЛӘ КОЯШ

Кояш әйтте: «Һаман мин яктырырмын
Вә бер дә батмамын, янып торырмын».

Диде Яңгыр да: «Һәр көнне явармын,
Кара җирне юешләр, елгалармын».

Кояш каршы диде: «Син бик юешле,
Явасың былчыратып һәммә төшне.

Суыңнан анда баткак, монда баткак, –
Синең бар белгәнең – җир былчыратмак.

Юешлектән иген, ашлык черидер,
Мужиклар, яумасайде[1], дип телидер».

Диде Яңгыр җавапта: «Син кызасың,
Игенне яндырасың һәм кырасың».

Ачуланды Кояш бу сүзгә, кызды,
Ачудан эсселектә хәттән узды.

Диде: «Мин бит җимешләрне пешергән,
Нурымнан җанлы-җансыз файда күргән».

Диде Яңгыр: «Аларны син пешерсәң,
Ә мин бит үстерәм һәм су эчертәм.

Әгәр мин яумасам, багълар[1] шиңәрләр,
Болынлыклар, яшеллекләр кибәрләр».

Кояш Яңгыр белән бик күп кычкырышкач,
Бере берсен яманларга тырышкач, –

Татулашты, килештеләр ахырда
Бу көннән соң сүз көрәштермәскә бер дә.

Шулай бетте боларда сүз вә тартыш,

Күрергә булдылар нәүбәт[2] белән эш.

Кояш әйтте: «Кызам үз нәүбәтемдә,
Ә син яу рәхмәтеңлә[3] нәүбәтеңдә».

Кояш, Яңгыр әле бу көнгә чаклы
Бозып эш кылмыйлар бу иттифакны[4].

## ЧЫРШЫ

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә[1] төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

## КЫШКА БЕР СҮЗ

Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз – язның алтын фәйтуны[2].

Тиз югал, әй Кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер күрсәң качарсың язны – гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык, кылыч-алмазлары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

## КӨЗ

(*Өзек*)

Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Мисале зәгъфыран[1] саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.

Такыр калды татар башы кеби[2] кыр;
Азык эзли – оча тургай да пыр-пыр.

Чыгып баш калгыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.

Кояш та яктысын киметтe шактый;
Тәәссеф[3]! Басты золмәт[4], китте якты.

Колакны шаулата инде суык җил,
Тулып эчкә өрә, мисле куык[5], җил.

Ничә әйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

**ҖИР ЙОКЫСЫ**

Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга[1] талган.

Ул тормас, йоклар,
Кышлар үтмичә,
Кыйбладан кошлар
Кайтып җитмичә.

Язның айлары,
Апрель, майлары,
Бик матур сызлып
Аткан таңнары;

Урман шаулавы,
Кошлар сайравы,
Күкләр күкрәве,
Яңгыр аннары.

Койну көн саен
Кояш нурында;
Аннан соң тагын
Төшкән чык төндә.

Бу хәлләр җиргә
Барчасы бергә
Калган тик инде
Төштә күрергә.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш,
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш!

**СӨТКӘ ТӨШКӘН ТЫЧКАН**

Ничектер, белмимен, беркөн идән асты кошы – тычкан
Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән.

Йөзеп йөри табакта арлы-бирле, – һич чыгып булмый!
Сыек сөт бит – бата, һич тә табактан ычкынып булмый.

Йөри тычкан, йөзәдер, тик торып булмый, йөрәк түзми;
Йөзәдер аркылы, буйга, – котылмактан өмид[1] өзми.

Тырышмак бушка китми бит, бераздан соң була уңай:
Бу тычкан шулкадәр йөзгән, куерган сөт тә – булган май.

Хәзер бит батмый, – тычкан, кирелеп, майга аяк баскан;
Сикергән дә табактан ул, чыгып, үз урнына качкан.

*

И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабырлык, күрсәт чыдамлык һәм ит гайрәт, сөбат[2]!

**ЕЛНЫҢ ДҮРТ ФАСЫЛЫ**

(*Русчадан*)

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде,
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? –
Йә, әйтеп кара!
(*Яз көне*)

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура, –
Бу кайчак була?
(*Җәй көне*)

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була?
(*Көз көне*)

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран,
Бу кайчак, туган?
(*Кыш көне*)

**ПАР АТ**

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.

Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.

Берзаман ачсам күзем, бертөрле яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин, болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.

Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Аһ! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын вә калфагын!

Әллә нәрсәм юк кеби; бернәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.

Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер – берсен дә белмим, әллә кем!

Сездән айрылып, туганнар, җайсыз, уңайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору.

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты китте яшьләрем.

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан!»

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан[1],
монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

**САБЫЙГА**

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз – аларның булганы юктыр гомер.

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искелектән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйранә ялган ул.

Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.

Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

**БИШЕК ҖЫРУЫ**
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем[1] син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

**ШҮРӘЛЕ**

**I**

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – «Кырлай» диләр;
Җырлаганда, көй өчен, «тавыклары җырлай» диләр.

Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.

Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.

«Зурмы?» – дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр[1].

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр, килеп,

Киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.

Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары[2].

Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Биниһая, бихисаптыр[3], гаскәри Чыңгыз кеби.

Кылт итеп искә төшәдер намнары[4], дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре[5].

Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә – Хакның бәндәсе.

**II**

Җәй көнен яздым бераз – язмыйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.

Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын, куркып, еракларга китәр дип уйларым...

Тукта, мин юлдан адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит «Шүрәле».

Аз гына сабыр ит әле, и кариэм[1]! Хәзер язам;
Уйласам аулымны, гаклымнан да мин хәзер язам.

**III**

Билгеле, бу кап-кара урманда һәрерткыч та бар;
Юк түгел аю, бүре; төлке – җиһан корткыч та бар.

Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши;
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.

Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр;
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.

Һич гаҗәп юк, булса булыр – бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас дисең – очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

**IV**

Шул турыда аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле;
Гадәтемчә, аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.

Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер егет
Киткән урманга утынга ялгызы, бер ат җигеп.

Тиз барып җиткән егет, эшкә тотынган баргач ук;
Кисә башлаган утынны балта белән тук та тук!

Җәйге төннең гадәтенчә, төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.

Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.

Балтасы кулда, егет эштән бераз туктап тора.
Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.

Сискәнеп, безнең егет катып кала аягүрә;
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.

Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!

Борыны кәп-кәкре – бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да – ботак-тармак кеби.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел – көндезләре.

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;

Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.

Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз төзен;
Тик килешсез: һәрбере дә ярты аршыннан озын.

**V**

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»

– Бер дә шикләнмә, егет, син, мин карак-угры түгел;
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугры түгел.

Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм.

Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр, көлдереп, адәм үтергән чакларым.

Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь егет! Килче, икәү уйныйк бераз кети-кети.

– Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый уйныймын;
Тик сине шартыма күнмәссең диеп мин уйлыймын.

– Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм!
Тик тиз үк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.

– Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.

Мин дә көч-ярдәм бирермен, әйдә, иптәш, кузгалыйк;
Шул агачны бергә-бергә ошбу арбага салыйк.

Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы;
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!

Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире;
Китте кушкан җиргә, атлап адымын эре-эре.

Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын, –
Кариэм, күрдеңме инде яшь егетнең кармагын?

Суккалыйдыр балта белән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.

Шүрәле тыккан кулын – селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан[1] хәйләсен һич, балтага күз салмыйдыр.

Суккалый торгач, ахырда, чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.

Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра;
Сызлана һәм ярдәменә шүрәләләр чакыра.

Хәзер инде Шүрәле безнең егеткә ялына;
Тәүбә итеп эшләреннән, изгелеккә салына:

– Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәмгенәм;
Моннан ары үзеңә, углыңа, нәселеңә тимәм.

Башкалардан да тидертмәм, ул – минем дустым, диеп;
Аңар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.

Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?

Тибрәнә дә йолкына, бичара, гаклыннан шаша;
Шул арада яшь егет өйгә китәргә маташа.

Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын[1] асла[2] колакка элми дә.

– И егет, һич юк икәндер мәрхәмәт хисең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! кем син? исмең кем синең?

Иртәгә килгәнче дуслар, тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты, диярмен, сорсалар[1].

– Әйтсәм әйтим, син белеп кал, чын атым Былтыр минем;
Бу егет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!

Шүрәле фөрьяд итәдер: аудан ычкынмак була
Һәм дә, ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була.

Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»

Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
– Син юләрсең, син котырган, син тилергәнсең, – диләр.

Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык белән тыел!
И юләр! кысканга былтыр, кычкыраламы быел?!»

## СУ АНАСЫ

(*Бер авыл малае авызыннан*)

### I

Җәй көне: эссе һавада мин суда коенам, йөзәм,
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде, шаять, бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, юк янымда юлдашым.

Бервакыт, китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам, бер куркыныч хатын утырган басмада.

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак белән утыра тузгыган сачын тарап.

Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,

Шунда яр буендагы куе агачларга посып.

Сачларын үргәч тарап, сикерде төште суга ул,
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.

Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага;
Җен оныткан, ахры, калган тарагы басмада.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга таракны тиз генә элдем дә мин.

Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам,
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба,
Аһ, харап эш! – Су анасы да минем арттан чаба.

Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!»

Мин качамын – ул куадыр, ул куадыр – мин качам;
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк, ичмасам.

Шул рәвешчә чабышып, җиттек авылга бервакыт;
Су анасын куарга күтәрелде барча эт!

«Вау» да «вау» да «һау» да «һау» –
бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.

Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем,
И явыз карчык! тарагыңнан коры калдың, дидем.

Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым! –
дидем. –
Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым», – дидем.

Сөйләгәчтен кыйссаны[1], алды тарагымны әни;
Курка үзе, алса да, уйлый эченнән әллә ни...

**II**

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.

Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
«Шык!» та «шык!» – кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.

Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да, кузгалмыйм әле;
Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни.

– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә белән, и пычагым кергере!

– Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты синең углың карак!

Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм,
Калтырыйм, куркам. «Ходай, – дим, –
инде мин кайда барыйм?»

Һич өзлексез «шык!» та «шык!» безнең тәрәзәне кага;
Ул коточкыч сачларыннан чишмә төсле су ага.

Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып,
Атты да тышка, тиз үк куйды тәрәзәне ябып.

Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине.

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә, иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым.

## КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК ХИКӘЯСЕ

Борын заман бер Ир берлән Хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, –

Болар булган берсеннән дә берсе арык.

Әйтә беркөн Ире: «Кара монда, Хатын! –
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын, –
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
Ашап ята бушка гына алар азык».

Хатын күнде, диде: «Ирем, ярар, ярар,
Бу икене кумаклыкка булсын карар;
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,
Аларны соң асрап торып ни файда бар?»

Нишли инде мескен Кәҗә белән Сарык?
Булмый хуҗа кушканына каршы барып.
Икесенә бер зур гына капчык тегеп,
Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.

Китте болар. Бара, һаман бара, бара, –
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.
Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,
Юл өстендә үлгән бүре башын таба.

Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,
Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак,
Баш янында болар икәү тора куркып;
Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот!»

Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк».
Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».
Бүре башын кулга тотып кузгатырга
Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.

Озак торгач, шунда Кәҗә белән Сарык,
Бүре башын тоталмыйча куллар барып,
Башны икәү тотып ике колагыннан,
Юнәлделәр, капчыкларына эчнә[1] салып.

Бара болар. Тукталмастан һаман бара.
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.
Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык:
«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып.

Ут янына бүреләр дә киләлмәсләр,
Безнең анда кунганлыкны беләлмәсләр».
Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде:
«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде».

Кәҗә, Сарык ут янына якын барса,
Мескеннәрнең күз алдында менә нәрсә:
Өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка,
Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка.

Кәҗә, Сарык, күргәч ошбу тамашаны,
Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.
«Исәнмесез, дуслар, бүре әфәнделәр!» –
Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.

Куаналар өч-дүрт бүре моны күргәч,
Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:
«Ашыйбыз, – дип, – бу икәвен тотабыз да,
Менә ничек ит таптык, – дип, – буткабызга!»

Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;
Ул ит белән һәркайсыбыз булырбыз тук!
Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!
Капчыктагы бүре башын китер алып».

Сарык шунда капчыктагы башны ала, –
Барча бүре куркуыннан шашып кала;
Өч-дүрт бүре хәйран калып торган чакта,
Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана.

Кәҗә әйтә: «Микикики! Микикики!
Капчыктагы бүре башы бит уники!
Ах, уңмаган, юләр Сарык, надан Сарык,

Моннан зуррак бүре башын китер табып!»

Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә шул ук башны.
Өч-дүрт бүре чынлап инде куркыштылар,
Бер-беренә күзләрене йөртештеләр.

Түгел хәзер бүреләргә ашау кайгы,
Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы;
«Ничек качыйк? Ничек табыйк качу юлын?» –
Һәрбер бүре шуңар салган бөтен уен.

Торып әйтә шул арада өлкән бүре,
Картайган һәм күп эшләрне үткән бүре:
«Туктагыз, – ди, – мин тиз генә су китерим,
Суы бик аз, безнең бутка пешәр коры».

Шулай итеп, өлкән бүре суга китә.
Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә.
Кайтмый бүре – эзе дә юк, исе дә юк;
Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә.

Бүреләрне тагы каты курку басты,
Чөнки хәзер башлыклары китеп качты.
Тагын берсе суга таба китте торып:
«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм», – дигән булып.

Мәгълүм инде, бу бүре дә кача шулай,
Хәйлә белән качарга юл ача шулай.
Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә;
Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә.

Өч-дүрт бүре берсе соңра кача берсе,
Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе.
Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык
Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып.

Утыралар аяк бөкләп каршы утка,
Болар инде тәмләп кенә ашый бутка.

Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына
Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна.

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук,
Кулларында бүре башы салган капчык,
Тагын болар урман буйлап сәфәр итте, –
Нәрсә языйм? Хикәям дә шунда бетте.

**ТАЗ**

(*Бер авыл малае авызыннан*)

Мәдрәсәдә бар иде бер Таз малай, –
Бик шаян, шуклык белән мөмтаз[1] малай.

Бик тирән – башындагы каткан бүрек,
Бер дә салмый, булмый һич башын күреп.

Кайсы чакта бүркен алып ташлыйлар:
«Әй, кояш чыкты! Кояш чыкты!» – диләр.

Ул заман без барчабыз бик кечкенә,
Зурыбызга яшь булыр унөч кенә.

Башчыбыз – Таз, берзаман без уйнадык;
Һичберәү күрмәс әле дип уйладык.

Аһ, бәла! Безне казый[2] күргән, имеш,
Уйнаганны ул карап торган, имеш.

Кәйфебезне бик тиз үк кыскартты ул,
Безне шул чактук[3] хөкемгә тартты ул.

Куркышып, казыйга тезләндек хәзер,
Төрле юл котлырга[1] эзләндек хәзер.

«Казый абзый! Безне син кызган», – дибез;
«Һәр усаллык башы шул Таздан», – дибез.

«И кизү! Бар, тиз китер, ул кайсы Таз?
Мин башын кашыймчы ул Тазның бераз».

Килде Таз. Без тик торабыз куркышып,
Барчабыз бертөрле хәсрәткә төшеп.

Кушты казый: «Ят! Сузыл! И Таз пәри!
Талчыбыктан сез котылмассыз әли», –

Дип, казый безне дә куймый шелтәли;
Шулвакытта Тазга талны селтәде.

Бер-ике сукты казый, – бу нинди эш?
Бер дә чаж-чож итмидер суккан тавыш.

Нәрсәдер бар монда – бер алдау эше,
Иштеләдер каты нәрсә тавышы.

Нәрсә бар? Таз аркасында нәрсә бар?
Камзулын Тазның күтәреп баксалар:

Хәйлә икән монда да ул Таз явыз, –
Белмәгә мөмкин рәсемгә баксагыз![1]

Казый абзый куйды шаркылдап көлеп,
Гайрәте сүнде, кызык эшне күреп.

Безне гафитте[2], сугалмый калды ул,
Талчыбыкка яткыралмый калды шул!

**ИСЕМДӘ КАЛГАННАР**

*Мөкаддимә*[1]

Бу «Исемдә калганнар»ны язуыма башлыча сәбәп берничә нәширләрнең миннән тәрҗемәи хәлемне язып бирергә үтенүләре булды.

Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрле тәрҗемәи хәлемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте.

Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы,

шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде.

Шунлыктан Уральскига килеп җиткәнемә кадәр кичергән хәлләр илә аннан соң хәзер шушы юлларны язып утырган вакытыма кадәрге башыма килгәннәрне икесен ике рисалә[2] итеп чыгарырга мәгъкуль[3] күрелде[4].

*Г.Тукаев*
*29 сентябрь, 1909 сәнә[5]*

**I**

Минем атам Мөхәммәтгариф, Кушлавыч авылында Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы булып, ундүрт-унбиш яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп, анда укып тәмам итәргә гадәттә ничә ел кирәк булса, шулкадәр торып, карт атасы тере вакытта ук авылыбыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр.

Мулла булгач та өйләнеп, бер җәмәгате илә берничә еллар гына торгач, җәмәгате вафат булып, бер ир вә бер кыз баласы калмыштыр.

Моннан соң атам, икенче мәртәбә өйләнеп, Өчиле авылы Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызын (минем анамны) алмыштыр. Минем туганыма биш ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып үлгән.

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам, мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна исемле авылның мулласына кияүгә чыккан...

Бу вакыт атамның ата-анасы (бабай вә әби) күптән вафат булып, авылда башка туганнарым булмаганлыктан, мин бу карчык өендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән, тәрбияләү генә түгел, яшь бала ларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-ике ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем балалык вакытымны күргән карчык вә хатыннар тәрбияче карчыгымның минем белән бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәят итәләр.

Җөмләдән берсе[1].

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага гына түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең: «Кадалмас әле килмешәк!» – дигән «шәфкатьле»

фикере илә[2] мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән...

Ул карчык үлгән инде; Аллаһ аңар рәхмәт итсен.

Мин бу карчыкта торган вакытта, анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк, ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәргән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән минутларда мин бала булсам да, хәзер дә атта утырып Саснага барганымны, үземне киң вә рәхәт галәмдә[3] хис иткәнемне, юлда барганда, күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвешле бардым, мине кемнәр каршылады – анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

Мин монда, әнкәмнең җеназасын[1] күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә капка астыннан үкереп елый-елый йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә хәтерләвемне язамын.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле авылындагы анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чакта ук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңа ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

Өчиле авылы (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә бик ярлы бер авыл булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык булганга, бабайның көнкүреше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган гаилә эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине еласам – юатучы, иркәләним дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

Бу гаилә эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә көннәр үткән, мин, монда торганда, чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Саҗидә исемле кыздан

башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде», – дип кенә караганнар.

Мин әле хәзер аерым әйттекем Саҗидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине юатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башладисә, хәзер күземә аппак саф бер фәрештә күренә.

Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган – һәрничек мин бу гаиләгә сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик, Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» – дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине асрау бала итеп өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдырмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле.

Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә иде.

Әти толчокта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда – анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни, Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Мин байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби[1] суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны[2] күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга туры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып, агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем – акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Аннан соң җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз йоннары куып йөргәнемне, арыгач, Хан мәчетенә[1] юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә – икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк», – дип, теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине янәдән аңарга утыртып, Өчиле авылына җибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу гаиләнең мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмет кисеп, кая булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән.

Бу урыннан башлап тәрҗемәи хәлемне үземнән хикәя итүне күңелем хаклы тапканга, «булган»ны «булды»га, «йөргәнмен»не «йөрдем»гә... алмаштырам.

**II**

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар. Тагын да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә йөгергәләп йөриләр иде.

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың», – дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине юатып бара иде.

Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, тирә-яктагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш, икенче яктан тагын рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты басу

капкасыннан кергәч күп ерак түгел икән, аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган[1], минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты, мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. Кергәч тә әнигә эндәшеп: «Хатын, бар, балага катык белән ипи китереп бир», – дип әмер итте.

Әни дә, шунда ук баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин, анда чыгып, адашудан куркып артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар, һәр көн авылның бер башыннан бер башына йөгереп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да, мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан әнинең миңа, сагынмаклык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар, мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда ике җиткән кыз күрдем.

Боларның берсе таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар, аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар – апайларың: берсе Саҗидә апаең, берсе Сабира апаең, күреш!» – дигәч, мин, әкрен генә барып, кулымны суздым.

Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Саҗидә атлы икән. Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән дә таныштым.

Сәгъди абзыйның юлда әйткәненчә, вакыйган, монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяҗ юк иде.

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар белән авыл буенча йөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем. Әгәр көндез кайвакыт уен арасында карыным ачса, тиз генә өйгә кайтып, ян тәрәзәдән генә өйгә кереп, әнинең минем өлешкә калдырган бер җамаяк бәрәңгесе илә бер

телем икмәген ашый идем.

Алар, әбәттән (көндезге аштан) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, ян тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше калмаганлыктан, без бакчадагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без шунда ук киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мескеннең, орышып, тешен кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар белән вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. Бу нидән икән дип уйлап торгач, Сабира апаның идәннән сәкегә котырган шикелле йөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди котычкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.

Ул төнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма:

– Сабира апаң вафат булды, син йоклап ятасың, тор, тор! – дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам, каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел – йокы тәмле булса да, сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, әнинең әтигә:

– Менә, «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул, мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! – дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Аннан соң кайчакларда әнинең йә кушкан йомышын тыңламасам, йә җиренә җиткерми эшләсәм, шул сүзне әйткәли торган иде.

Әти белән без бик-бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде.

Мәсәлән, минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиларым тузгач, әти мин килмәстән бер ел элек үлгән улының күк киндер күлмәге белән бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда әни: «Мин үз улымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк», – дип, бик озак тарткалашты.

Ахырда әти: «Йә, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр ялангач йөртерсеңме?» – дип, киемнәрне көчләп диярлек миңа

алып киертте.

**III**

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казыр вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә туры килмәде: миңа казып чыгарылган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай, аякны балчыкка күмеп бәрәңге чүпләгән чагында, теге бәрәңге казучы аксак Саҗидә апай ялгыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә, урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып егъладым да, соңра җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемдә дәвам иттем, ләкин бу юлы аяклар никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

(«Моны ни өчен яздың?» – диярләр. Ни өчен яздым? Шулвакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга, тоттым да яздым.)

Бара торгач, бакча эшләре дә бетте.

Беркөнне кич белән әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты, кояш чыкмас борын ук торып чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек, мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында минем яшемдәге кечкенә кыз балалар булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богдай арасындагы берничә борчак кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк белән бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.

Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, би, ти, си, җом, хи»ны бер дә тартынмыйча кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә, «әлеп, би, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарты»[1] да тоттырдылар.

Бу «Иман шарты»ның иҗеге белән сүрәсе[2] миңа кыш буена җитте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарты» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать «Иман шарты» бетерүгә гыйлавә[3] буларак, бервакыт, абыстай

өйдә юк вакытта, бәгъзе[4] шаян кызларның «Кәлимәтен тайибәтен, безнең әни бай хатын, изүе тулы тәңкә, борыны тулы...» дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем[1] булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап[2], аларны көлдереп йөрер булдым.

**IV**

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр, тәмам кардан ялангач калып, карала башладылар.

Менә бераздан Сабан туе җитте. Мине Сабан туе көнне иртә үк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген Сабан туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, ятим калган мулла баласы икәнемне искә алгач, миңа башка малайларга биргән кеби конфет, бер-ике прәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буяган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем.

Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыгым болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы – анысын белмим, капчыкны әнигә бирдем дә, үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл егетләре, авыл кызлары, ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан Сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без, яланаяклы малайлар исә, аның артыннан бер дә калмыйча йөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы – хатын-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышлар башланды.

Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак прәннекләр хисапсыз иде. Болар арасында егетләр тарафыннан кызларга бирелергә иң муафыйгы[1], әлбәттә, кызыл билле ак прәннек инде.

Чөнки ул прәннек хакында бер авыл җыруы да бар. Болай:

Болынлыкка бөркет килгән,
Куркытадыр казларны;
Кызыл билле ак прәннек
Кызыктыра кызларны.

Атлар да чабышты. Малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды, шулай итеп, Сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде – бу Сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, өч-дүрт көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби йөгереп, уйнап үткәрә алмадым, чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы юатып, тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте, үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мин бер малайны бу ел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем уйныйсы килгән балалар өчен зур газап булган нәрсә – эш белән үтте.

Бу бала тугач, әтинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды. Шөйлә ки[1], мин үз өлешемә тигән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым.

Җитмәсә тагы, теге аксак кыз да: «Үз энем! Җан энем!» – дип, Садрины юри мине кәефсезләндерер өчен сөйгән була иде.

**V**

Көз җитте. Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр.

Мин, мәдрәсәдә «Һәфтияк» иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга[2] кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылыбызның бер бай баласы да булып, ул мине, хәлфәсе кебек итеп, чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да йорт хезмәтләренә дә ярый башладым.

Мәсәлән, иртә белән менеп морҗа ачу, аннан соң морҗа ябу, мичкә ягар өчен салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кебек эшләр – һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Кайвакыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең

хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман әтинең шәриге[1] йә дусты булганмы, нидәндер миңа атна саен биш тиен акча бирә иде.

Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Әти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне әниеңә дә калдыр», – дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, «ярар» дия торган идем. Ләкин ул күмәч, авылга кайтып җиткәнче, вак-вак кына капкаласам да, әнигә кала идеме, юкмы – хәтерләмим.

Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләргә[1] озаграк туктарга туры килде.

Шуның өчен хәзер андагы үзгәреш вә истә калганнарны берничә җөмлә белән генә язам да Кырлайдан чыгып китәм.

Саҗидә апай, чахотка белән бик озак авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда, аны әти үзенең аркасында күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде. Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чагында, кисәктән килгән бер авыру эләктерде. Аның шунда ук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты», фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр. Әти бу авыру сәбәпле эштән калмады, тик бер аягы гына чатанлап йөрүчән булып калды.

Бервакыт, көз көне, өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин ян тәрәз төбендә «Рисаләи Газизә»[2] укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә, миңа эндәшеп: «Әти-әниең кайда?» – диде. Мин: «Ындырда», – дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт», – дигәч, мин, тиз генә ындырга йөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра», – дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр, мөсафир[72] белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына нидәндер мине дә утырттылар вә, гадәткә каршы буларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдегез?» – дигән сөаленә[1] каршы мөсафир: «Менә бу баланы алырга килдем», – диде. Бу сүздән әти, бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул? Ник син алырга килдең?» – дип, сөальләр бирә башлагач, мөсафир бу рәвешчә сүзгә башлады: «Мин – Кушлавыч кешесе. Бу бала – авылыбызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән хәбәрсез идек, менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек[2] каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе

бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр кулында йөргүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакыртмакчы була. Менә мин быел Җаектан, аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм», – диде.

Мөсафирның бу сүзләренә этинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте. «Ярар менә, без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны өч-дүрт ел ашатып торыйк та, хәзер эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән?» кеби сүзләр илә нык тартыштылар.

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!» – дип куйгалый иде.

Мөсафир Бәдретдин абзый: «Юк, сез не имеешь право кеше баласын тотып торырга, мин хәзер үрәтниккә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне подсуд җибәрермен», – дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара эти-әни йомшардылар.

Бераздан, минем тату тормаган әнием: «Йә, атасы, бирик инде, ахры, кеше баласы безгә булмас, Алла сакласын, әллә ниләр күрербез», – дип, үкереп елап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соңра бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, эти дә риза булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми, мине арбага чыгарып утырттылар.

Эти-әни, бичаралар, һәр икесе егълаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың[1]», – дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек. Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә, авылдагы иптәшләр вә таныш-белешләр илә күрешә алмадым. Алар белми калдылар.

Без юлга чыккач, күп тә үтми кич булып, караңгы төшә башлады.

Юлда Өчиле авылына – бабайларга төштек. Анда чәй эчтек. Бу гаиләнең һәммәсе мин күргәндәгечә бергә торалар, фәкать Саҗидә апай гына кияүгә киткән иде.

Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларын үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек.

Юлда килә-килә, мин арбада шактый ватылган булырга кирәк, Бәдри абзыйның өенә кергәч тә, эреп йокладым.

Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем. Бу өйнең эчендә табак-савыт, кашык-чүмеч, камыт-эшлея кеби нәрсәләр генә булып, җиһаз-фәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.

Чәй эчтек. Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14–15 яшьлек бер угылы вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде.

Чәйдән соң өйдән чыгып, аңа каршырак салынган ак өйгә кердек.

Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый. Стеналары сап-сары нараттан, җиһазлары вә язу өстәлләре авыл кешесе өчен җитәрлек иде.

Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, богдай, арышларны күргәч, мин аның бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем[1].

Тагы Камалетдин миңа, күз җитү сәбәпле, яме киткән булса да, умарта оялары белән тулган шактый зур бакчаларын да күрсәтеп йөрде.

Мин инде, бер кергәч, бу ак өйдән чыкмас булдым вә шунда куна да башладым.

Кич белән китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел-җөләса»[2] китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә» вә «Сөбател-гаҗизин»нәр[1] генә укыганда, бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләнәм вә китапта шундый сүзләр дә була микәнни дип үземә сөаль бирә идем.

Кайчакта мин, шул «Фәвакиһел-җөләса» тәэсире илә, Гайшә абыстайның кер юган җиренә – кара өйгә барып, аның белән кычкырыша торган идем. Ул ирләрне мыскыллый иде, мин дә үз нәүбәтемдә хатыннардан көлә идем.

Кая барсам да, мине мулла баласы дип, халык башка малайлардан аерганга, хәтта җыеннарда яшьтәш кызларым илә «таккаравыл» уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.

Мәсәлән, берзаман Бәдри абзыйларга килгәч, минем илә күрешергә Ситдыйк исемле, авылыбызның шактый могтәбәр[2] кешесе килде, үзе исерек иде.

Миңа килеп сәлам бирде – сәламен кайтармадым, кулын сузды – кулын алмадым.

Сәбәбен сорадылар. Мин шулвакыт «Бәдәвам»ның:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә, һәм син алма... –

дигән бәетен ярдым да салдым. Моңар бөтен Бәдри абзый гаиләсе гаҗәпләнүдән башка, минем бу диндарлыгым авылга да җәелде.

Бәдри абзый, мине өенә алып кайткач та, үзе бер эш белән Казанга китте.

Ул анда бер ай торган вакытта, мин дә буш ятмадым. Камалетдин илә бергә авылыбызның мәдрәсә шикелле бернәрсәсенә барып, сабак

укыдым. Күп вакыт кунып укырга да туры килә иде.

Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене «гыйлем» итә торган кеше булырга кирәк ки, шул аз вакыт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп, калтырап торганым бар.

Кайчан да булса бервакыт бу хәзрәт таягының миңа да эләгү ихтималы мине куркытканга вә, таң белән, шәкертләр белән бергә кунып, иртә намазына бару бик авыр булганга, эчемнән: «Ай, Бәдри абзый кайтса, тизрәк Җаекка китәр идем», – дип көтә идем.

Берзаман Бәдри абзый кайтты. Миңа яңа бүрек, яңа киезката, яңа бишмәт алып кайткан.

Мин бу яңаларны бик зур куанычлар илә кидем дә үземнең иске киемнәремнән бүрегемне, «бервакыт кайтып карармын» дип, чормага яшереп, саклап куйдым. Бу да гаҗәп эшләремнән берсе булды.

Шуннан соң Кушлавычта берничә көн генә тордык та Бәдри абзый белән Җаекка таба юнәлеп чыгып киттек.

Бер тәүлек кадәр баргач, Казанга килеп кердек (Печән базары тирәсе булырга кирәк), бер урынга туктадык.

Шулвакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше йөгереп килә[1].

Бу, минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде, әйдә, өйгә алып барыйм: чәй эчәрсең, бездә кунарсың», – дип, мине алып китте.

Өйгә барып кердем. Анда әни[1] каршы алды. Бичара, сагынган икән, ул да егълады.

Минем өчен хәзер чәй куелды. Әти харчевнядан пилмән алып чыкты: сыйландык. Миннән моңа кадәр ниләр күргәнемне сораштылар. Мин дә онытмаган кадәрене сөйләдем...

Бу ата-анамның, мин аерылып торган вакытта, әтинең сакалы агаруы вә әүвәл Яңа бистәдә булып, хәзер Иске бистәгә күчүләреннән бүтән үзгәреш күренми иде.

Ул кичне шунда кундым. Иртәнге чәйне эчкәч, әни мине ләгәнгә утыртып юындырды. Яхшы күлмәк-ыштан кидерде. Яхшы кәләпүш һәм кыш көне барачак минем озын сәфәрем өчен кирәкле булган бер тире чалбар китерде. Ул мине номерга Бәдри абзый янына озатканда, тагын сагынмаклык итеп, тәсбихләр вә «Мәрьям ана»лар[2] бирмәкче булса да, мин: «Кирәкми, берсе дә кирәкми, мин бай җиргә барам», – дип, нидәндер кабул итмәдем.

Без торган номер бик начар да, бик яхшы да түгел, уртача гына бер номер иде.

Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән иде. Шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна

кадәр шул кешене көтеп яттык.

Ниһаять, безнең көткән Алты-биш Сапыебыз килеп, без торган номер күршесенә төште.

Ул килеп берничә көн торгач, Бәдри абзый мине аның номерына күчерде дә, үзе миңа алты данә икешәр тиенлек унике тиен акча биреп, авылга кайтып китте. Мин Бәдри абзыйдан тагын бер генә көн торуын үтенсәм дә, аннан бер дә аерыласым килмәсә дә, ул мине төрле сүзләр илә юатты-юатты да китеп барды.

Ул киткәч, мин Алты-биш Сапый вә хатыны янында калдым.

Бу шәһәрдән килгән кешенең киемнәре вә сөйләшүләре миңа ят тоела иде.

Мәсәлән, ул сүз арасында «мин өлкән кеше» дип ычкындырса, мин бу «өлкән» дигән сүзне һич аңлый алмый идем.

Алты-биш Сапыйның өстендә якасы вә җиңе камалы төлке тун булганга, «өлкән» кеше дип әллә шундый тун кигән кешегә әйтәләрме дип тә уйлый идем. Соңыннан, Җаекка килгәч, белдем ки, «өлкән» «олуг» дигән сүз икән.

Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә тозлы балык – вобла һәм симәнке алып ашадым.

Берничә көн торгач, Җаекка юнәлдек.

Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр. Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә, иркенгә чыгаралар иде.

Мин никадәрле: «Җәяү барсам да, тышта, иркендә барам», – дип гозерләнсәм дә, «Туңарсың, җизнәң туңдырмаска кушты», – дип, мине чыгармыйлар иде.

Җизни бу Алты-биш Сапыйга Казаннан әллә нинди бер яхшы чана алып кайтырга кушкан икән, шул чана безнең артка тагылган, һәм безнең алдан бара торган тагы төрле-төрле йөкләр төялгән Җаек кешеләре булганга, без «обоз» йөрүе белән бардык. Шул сәбәпле ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек.

Җаекта иң элек Сапый абзыйның өенә төштек. «Монда чәй эчик тә, җизнәңнәргә кичкә илтербез», – диделәр.

Кичкә таба, икенде-ахшам арасында, Сапый абзыйның җитәгендә җизниләргә киттем.

Юлда яшел чапан бөркәнгән яшь кенә бер хатын очрады. Алты-биш Сапый: «Бу – апаең, күреш», – дигәч, моның илә күрештем.

Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән, капкадан кереп, биек-биек баскычлардан менеп, өйнең икенче катына кердем.

## ҖИЛ ИЛӘ КОЯШ

Берзаман Җил илә Кояш икәве: «Кайсыбыз адәмнең киемен салдыра алыр?» – дип даулаштылар.

Җил, бар куәте илә исеп, адәмнең киемен салдырырга тырыша иде. Җил катырак искән саен, адәмнең киеме тәненә катырак ябыша бара иде. Җил булдыра алмады.

Менә берзаман Кояш күтәрелде. Баягы адәм кояшның кыздырганына чыдый алмыйча, барча киемнәрен култык астына кыстырып, ялангач китте.

## КӘГАЗЬ ОЧЫРТКЫЧ

Балалар җибәргән кәгазь очырткыч, җирдән аз гына күтәрелеп очкан күбәләкне күргәч: «Мескен, ышанамсың? Син миңа аз гына күренәсең бит. Син, бичара, минем бу кадәр югары очканыма, әлбәттә, көнләшә торгансыңдыр», – диде.

Күбәләк җавапта: «Юк, бер дә көнләшмим; аның өчен син, никадәр югары очсаң да, бәйләүдә генә очасың; минемчә, мондый гомер итү бәхеттән бик ерак булырга тиеш. Әмма мин, никадәр түбән очсам да, бәйләүдә очмыйм; минем үз иркем, теләсәм кая барам; мин, синең төсле, бөтен гомеремне берәүнең кәефе өчен фида итмим[1]», – диде.

## АРЫСЛАН ВӘ ТӨЛКЕ

Төлке, иң беренче мәртәбә Арысланны күргәндә, куркуыннан чак кына үлми калды.

Менә күп тә үтмәде, ул тагы Арысланны күрде. Инде Арыслан аның күзенә ул кадәр үк куркынычлы күренмәде.

Өченче мәртәбә күргән иде, инде Арыслан белән кара-каршы сөйләшергә үк башлады.

## *

Куркыныч һәрзаман ияләнмәгәнгә генә була. Бер ияләнсәң, куркыныч та гади нәрсә генә булып кала.

## ЧЫЛБЫРДАГЫ ЭТ

Бер ишегалдында ояда чылбырга бәйләнгән карт Эт тора иде. Ул бала чагында ук, шул чылбырда йорт каравыллап, Хуҗасына бик күп хезмәт иткәнгә, Хуҗа да бу Этне бик сөя иде.

Хуҗа, кайвакыт моның янына килеп: «Син мине яратасың, миңа тугры хезмәт итәсең бит, иншалла, мин дә сине ташламам», – дип әйтеп, карт Этнең күңелен шатландырып китә иде.

Кайчакта иректә йөри торган урам этләре, бу ишегалдына килеп, бу Этне котырталар вә үчеклиләр иде.

– Менә син Хуҗаңа хезмәт иткән буласың, бервакыт күрерсең әле: син картаеп эштән чыксаң, Хуҗаң сине йортыннан куар да чыгарыр әле, ашарга да табалмассың, – диләр иде.

Ләкин чылбырдагы Эт боларның сүзләрен, Хуҗаның эшен ташлап, үзенә көн күрергә киңәш бирүләрен тыңламады.

Беркөн бу Эт Хуҗасының йортыннан ут чыкты. Өй янып бетте, инде утның ялкынлы төтеннәре Эт оясына да җитә башлады. Бичара Эт бик каты курыкты: кызганыч тавышлар илә өреп, елап, ары-бире сугылып, чылбырны өзәргә азаплана башлады. Шулай булса да, аның эчендә «шаять, Хуҗам килер әле, мине коткарыр әле» дигән ышаныч һаман бар иде. Бара торгач, төтеннән сулыш алырга да читен була башлады. Мескен Эт чылбырны өзә алмый, аңа хәзер янып үләргә генә калган иде.

Шулай торганда, менә берзаман әллә кайдан, төтен арасыннан Хуҗа йөгереп килеп чыкты. Аның чәчләре, киемнәре, йөзе тәмам көйгән, бөтен җиреннән төтен чыга иде. Үзе шундый куркынычта булса да, ул, ничек тә булса утны ерып кереп, Этнең чылбырын чиште.

Эт, мескен, котылуы белән Хуҗасына ташланды: өрә, елый, Хуҗасының битен, кулын яларга башлады. Бичара Эт тик: «Рәхмәт сиңа! Мин синең мине карап торып һәлак итмәсеңә ышанган идем. Рәхмәт сиңа!» – дип әйтә генә алмый иде.

## БӘХЕТ

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр, эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, уңышсызлыкларын һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман Бәхет, күзгә күренмичә генә, боларга кунакка килде дә бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Бу вакытта өч агай-ененең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Дәрхаль[1] бәхетнең ярдәме илә ни сатса, аннан файда, ни алса, аннан табыш итеп, берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган бер зур бай булып

китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә[2] кятиб (писарь) иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек[3] дәрәҗәсенә күтәрелде; медальләр бирелде.

Сез инде, өченчесенә дә Бәхет ярдәм иттеме, диярсез. Хәзер, Бәхетнең булышлыгы илә, кулын селтәгән саен, чебен тота; һичбер селтәгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде, дигән идек бит. Дөрес, Бәхет озакламады, китте.

Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып теләнергә китте.

*

Укучы! Ошбу хикәядә кем гаепле икәнен үзең хаким булып табып хөкем ит.

## КӨЗГЕ ҺӘМ МАЙМЫЛ

Маймыл, көзгедән үзенең сурәтен күргәч, әкрен генә янындагы Аюга аягы белән төртеп:

– Кара әле, иптәш! Көзгедә нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер хайван күренә. Кара әле, аяклары нинди кәкре, кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем. Хәер, әйтергә мөмкин, минем иптәш вә дусларым арасында да бу көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак белән санап күрсәтә алам, – диде.

Аю моңар җавапта:

– И Маймыл иптәш! Син, иптәш вә дусларыңны санап мәшәкатьләнгәнче, бер мәртәбә үзеңә генә карасаң булмасмы? – диде.

## УМАРТА КОРТЫ ВӘ ЧЕБЕННӘР

Ике чебен, чит мәмләкәтләргә китәргә хәзерләнеп, үзләре илә бергә китәргә Умарта кортын да чакыра башладылар.

Бу чебеннәр чит җирләрнең бик яхшы икәнлеген байгышлардан ишеткәннәр иде.

Чебеннәр ник китмәсеннәр? Туган җирләрендә боларны рәнҗетәләр

һәм, чакырылмаган кунак шикелле, бичараларны ашъяулык тирәсеннән куалар, татлы ашларны да ашатмыйлар...

Һәммә ашамлык нәрсәләр өстенә пыяла калфаклар каплап, мыскыл иткән шикелле, тик чебеннәрнең күзләрен генә кызыктыралар.

Почмак тарафларына бөтенләй барыр хәл дә юк: анда усал үрмәкүчләр ау корганнар.

Онытылмасын әле, Умарта корты боларга ни җавап бирде? Ул: «Миңа туган-үскән җирем кадерле. Мин үземнең кәрәзле балым илә алпавытларны, байларны, хәтта авыл кешеләрен үземә гашыйк иттем. Мин монда да сөекле. Әмма сезгә сүзем юк, сез теләсәгез кая барыгыз. Ләкин белегез ки, сезнең һәр җирдә дә бәхетегез бер булыр; әгәр сез һаман хәзер ашны ашау гадәтегезне ташламасагыз, кая барсагыз да, сезне хөрмәт итмәсләр», – диде.

*

Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр.

**КЕШЕ ҺӘМ АРЫСЛАН**

Көчле булмактан гакыллы булмак кат-кат артыктыр.

Моңар ышанмаган кеше, менә бу хикәячекне укыгач, гакылның артыклыгына канәгать хасил итәр[1].

Бер Аучы үзенең авын агачлар арасына җәеп, нинди булса да табыш көтеп торганда, ялгыш үзе Арыслан тырнагына эләкте.

Арыслан, каһәрләнеп: «Бет, и бәдбәхет мәхлук! Менә минем тырнагымда тикшереп карыйк әле, синең тазалыгың вә көчлелегең кайда икән? Сез, адәм балалары, үзеңезне бөтен дүрт аяклы хайваннарга, хәтта Арысланнарга да, падишаһ дип йөрисез, имеш. Менә хәзер бу дәгъвагызның тиешле-тиешсезен карарга форсат табылды», – диде.

Бичара Аучы Арыслан тырнагыннан зәгыйфь кенә тавыш илә: «Без сездән көч вә куәт ягыннан өстенлекне дәгъва кыйлмыйбыз, бәлки гакыл илә сездән югарылыкны дәгъва итәбез; менә мактанырга батырчылык итәмен ки, мин хәзер бу җирдә үземнең гакылым илә шундый эш эшләрмен ки, сез ул эшне көчегез белән эшли алмассыз», – дигәч, Арыслан: «Сөйләмә! Мин сезнең мактанган әкиятләреңезне тыңлап ардым инде...» – диде.

Аучы: «Юк, падишаһым, әкият түгел, мин хәзер осталыгымны күз алдыңда күрсәтәм. Әгәр сүзем ялган булса, минем качып котылыр хәлем юк, соңыннан да ашарга өлгерерсең. Менә минем агач арасында җәйгән

үрмәкүч ояларым бар, шуның астыннан мин гакылым белән чыга алам, һәм син дә көчең белән чыгып кара. Әнә үзең дә күрәсең: ул – үрмәкүч оясы, таш стена түгел, әнә аз гына җилгә дә селкенеп торадыр».

Арыслан: «Җә, элек үзең чыгып кара!» – дигәч, Аучы мәһарәт[1] белән, шома гына, ау астыннан чыкты.

Аның артыннан Арыслан да, җәядән атылган ук шикелле сикереп, ау астына барып керде.

Әмма бәхетсез Арысланның ау астына гомердә дә кергәне юк иде. Мескин хайван ауга чорналып калды.

Гакыл көче җиңде.

Көчле Арыслан һәлак булды.

## ТЫЧКАН ИЛӘ КҮСЕ

– Күрше! Син бер шатлык хәбәр ишеттеңме? Мәче Арыслан тырнагына эләккән, ди, – дип, Тычкан йөгереп килеп Күсегә әйткәч, Күсе:

– Шатланма, күз нурым! Әгәр Мәче Арыслан тырнагына якынлашса, бер дә шиксез, Арысланны да һәлак итәр. Мәчедән көчле хайван юк, – диде.

*

Куркак берәүдән курыкса, үзе курыккан кешегә бөтен дөнья курку күзе белән карый дип уйлый.

## ЯШЬ АГАЧ

Мужикның урманда балта тотып барганын бер Яшь агач күрде дә, мужикка кычкырып: «И агай! Зинһар, хәлемә мәрхәмәт итеп, минем тирә-ягымдагы карт агачларны кисә күр; мин, алар каплап торганга күрә, якты дөньяны күрә алмыйм вә иркенләп, рәхәтләнеп үсә алмыйм; тамырларым да, шушы карт агачлар тыгызлаганга күрә, кирәгенчә җәелә алмыйлар. Миңа җил дә, кояш нуры да керә алмый. Әгәр син карт агачлардан мине коткарсаң, мин бер ел эчендә урманның беренче матур агачы була алыр идем, бөтен сахра минем күләгәм илә капланыр иде. Менә, күрәмсең, шул картлар зарарыннан минем калынлыгым һаман чыбык шикелле генә», – дип ялынгач, мужик үзенең беренче дустына хезмәт күрсәткән шикелле, безнең Яшь агачка ярдәм күрсәтмәкче булып, кулына балтасын ипләп тотып, аз гына вакыт эчендә теге карт агачларның һәммәсен кисеп - аударды.

Менә инде Яшь агачның күңеле булды, куанды, аңар дөнья иркен калды.

Ләкин бу куанулар урынлымы?

Хәзер инде бичара Яшь агачны кояш яндыра, йә бозлы яңгыр кәефен ала, йә ком, туфрак бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп, иелдереп китә.

Көннәрдән бер көнне бик каты җилле давыл килде дә Яшь агачны шартлатып сындырды да китте.

Бу хәлне күреп торган бер Елан, җилдә сынып яткан Яшь агачка карап: «И яшь бала! Инде кемгә үпкәләмәкче буласың? Бу бәла синең үзеңнән булды. Әгәр син карт агачларга тарланмаган булсаң, ул агачлар сине җилдән, яңгырдан саклаган булырлар иде; син ышыкта, тыныч кына, рәхәтләнеп үсәр идең. Гакылсыз! Ул агачларга да мәңгелек суы сипмәгәннәр иде, аларның гомере беткәнен көтсәң, аңарчы син дә үсеп, куәтләнер идең, үз нәүбәтеңдә син дә зур агач булып, дөньяны күреп торыр идең, һәм бу бәлаләр башыңа килмәгән булыр иде», – диде.

**ЯХШЫЛЫККА ЯХШЫЛЫК**

Күгәрчен, суда бер Кырмысканың батып һәлак булырга җиткәнен күргәч, дәрхаль[1] авызына бер яфрак капты да суга ташлады.

Кырмыска бу яфрак өстенә менде дә, дулкын яфракны яр кырыена сөреп чыгарып, Кырмыска үлемнән котылды.

Бервакыт Аучы бу Күгәрченне ауларга хәзерләнгәнен күргәч, Кырмыска, теге яхшылыкны исенә төшереп, Аучының итек эченә керде.

Аучы Күгәрченне аулыйм дигән чакта гына, Кырмыска Аучының ботыннан бик каты тешләде. Аучы авыртудан кулындагы авын төшереп җибәрде дә, Күгәрчен прррх итеп сәламәт очып китте.

**ЧАБАК**

Исемдә юк, нинди суның яр башындадыр, су патшалыгының дошманнары – балыкчылар – кармакларын салып, калкавычтан бер дә күзләрен алмыйча карап утыралар иде.

Мәгәр шул җирдә генә үз-үзен җитез һәм үткенгә санап йөргән вә үз-үзенә бик ышанган бер Чабак тора иде.

Чабак сукыр түгел, кармакны күрде. Менә ул кармак белән уйнарга тотынды: бер, ук шикелле атылып, кармак янына бара; бер артка китә; бер атылып китә дә, гүя балыкчыдан көлгән шикелле, суалчанның башыннан гына капкан булып тартып, үзе артка качып китә; янә килә дә кармакның

җебеннән азрак тарткалап китә.

Балыкчы исә, «әнә эләгә», «менә эләкте» дип, тик йөрәге сикереп утыра. Кармакны алып карый: очы күренә, салынган суалчан ашалган; янә сала, янә ала. Чабак та кармак янында кубар шикелле[1] әйләнә.

Шул рәвешчә балыкчы илә Чабак алдашып, хәйләләшеп торганда, бер күпне күргән Карт балык чабакка бу сүзләрне әйтә иде:

– И юләр Чабак! Син ни өчен һаман кармаклар тирәсендә әйләнәсең? Әллә сиңа суда урын беттеме? Гафил булма[2], син кармакка якынлашкан саен бәлагә якынлашасың! Әгәр бу сүземне тотмасаң, син, озакламыйча, безнең су илә бәхилләшерсең.

Гакыллы сүзне ахмакка әйт, чукракка әйт – икесе дә бердер.

Чабак бу нәсыйхәткә[1] каршы:

– И ата! Син юк нәрсәдән куркасың. Дөрес, кешеләр хәйләкәр, әмма мин аларның хәйләләрен ап-ачык күреп торам. Менә күрәмсең: монда бер кармак, әнә тегендә икенче кармак. Син, ата, карап тор әле: мин ничек балыкчыларны кызык итәрмен! – дип сөйләнә-сөйләнә, яшен шикелле атылып, бер кармакка барып ябышты.

Берсеннән китте, икенчесеннән үтте, аһ! өченчесенә барып эләкте! Инде качмакчы да булды, әмма соңрак иде.

## КАЗ

Каз, суда йолдыз шәүләсен күргәч, балык дип белде һәм ничә мәртәбә аны ауламакчы булып тырышса да, шәүлә урыныннан кузгалмагач, Каз да шәүлә икәнен белде дә аулауны ташлады.

Иртәгесен Каз суда чын балыкны күргән иде, ну, бу да кичәге кеби шәүләдер дип ачуланмады вә аңар әйләнеп тә карамады.

*

Безгә дөресне ялгыштан һәрвакыт аерырга кирәк, бу икенең берсен берсе урынына төшермәскә тырышырга кирәк.

## ИКЕ САБАН

Ике сабан, икесе бер үк тимердән, бер үк һөнәр йортында эшләнеп, базарга чыгарылганнар иде.

Боларның берсе иген игүчегә сатылып, ул аны алгач ук, эшкә кушты, – аның белән җир сөрә башлады. Шул рәвешчә бу сабан һәр җәйне эшләп,

аңар тик ятарга туры килми иде.
Икенче сабан исә, бер сәүдәгәр кулына эләгеп, аның кибетендә ауналып, эшсез ята иде.
Шулай озак заманнар үткәч, бу ике сабан бер җирдә очраштылар.
Кибетчедәге сабан, күп еллар эшсез ятканлыктан, тәмам тутыгып, саргаеп, караңгыланып беткән иде.
Иген игүчедәгесе исә күп эшләп ачылган һәм күзге шикелле ялтырап тора иде.
Тутыккан сабан, үзенең иптәшенең болай матурланганын күргәч, аннан:
– Иптәш, син ни сәбәптән болай ялтырыйсың да, мин ни сәбәптән мондый тутыккан һәм караңгыланган? – дип сөаль бирде.
Икенче сабан аңар:
– Минем ялтыравым тырышуымнан килде. Әгәр гомерем буе кибет идәнендә кырын ятып торсам, мин дә синең төсле каралыр һәм ямьсезләнер идем, – дип җавап бирде.

**ФИЛ**

Фил ничектер падишаһ Арыслан каршында зур хөрмәткә ирешкән.

Моның болай дәрәҗәгә менүе урмандагы хайваннарга таралгач, алар: «Бу Фил карарга матур да түгел, сөйкемле дә түгел, ул кай җире белән Арыслан каршында хөрмәт тапты икән?» – дип, гаҗәпләнеп сөйләшә башладылар.
Шул арада төлке, койрыгын болгап: «Әгәр Филнең койрыгы минеке төсле матур, мамыклы вә алтын төсле булса, мин аның дәрәҗәгә менүенә бер дә гаҗәпләнмәс идем», – дигәч, Аю да, сүз башлап: «Әллә Филнең тырнаклары зур һәм үткен булганлыктан, ул Арысланга ошады микән?» – диде.
Башкалар сөйләгәндә, мин нигә карап торыйм дидеме, Үгез дә: «Ул Филнең борыны астында ике ак сөяге бар бит, Арыслан аны, бәлки, мөгез дип белгән булыр», – дигән генә иде, бер яктан Ишәк тә, чабата чаклы колакларын селкеп: «Мин беләм, әгәр Филнең колаклары зур булмаса, асла[1] ул дәрәҗәләрне таба алмас иде!» – диде.

*

Без, макталган кешенең колакларын, борыннарын билгеләмәсәк тә, аңар катыштырып, үзебезне макташтыргалыйбыз.

**ӘТӘЧ ИЛӘ ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ**

Чүплек башларында казына торгач, Әтәч ничектер бер энҗе бөртеге тапты да үз-үзенә сукранып сөйләргә тотынды: «Энҗе, дигән булалар! Бу энҗе нинди юк нәрсә! Әгәр бу табылганчы, миңа, казып мәшәкатьләнгәнем өчен, бер тары ярмасы табылган булса, мин нинди шат булыр идем».

*

Түбән фикерле кешеләр, нәрсәләрнең кыйммәтен белмәгәнлектән, күп вакытта шушы Әтәч кеби хөкем итәләр.

## СУКЫР ТЫЧКАН ҺӘМ КАРАКОШ

Ерак җирләрдән килеп, Каракош илә хатыны бер кара урманга кереп, бер карт имәнгә оялап, бөтен гомерләрен шунда үткәрмәкче булдылар.

Бервакыт үзләре сайлап тапкан бер карт имәнгә оя ясап, җәй буе шунда балалар үстерергә уйладылар.

Боларның бу ниятләрен ишеткән бер Сукыр тычкан Каракошка:

– И кошлар падишаһы! Бу сез оялаячак имәннең төбе чергән, тиз заманда авып төшү ихтималы бар. Мин сезгә бүтән агачка оялауны мәслихәт күрер идем, – дип киңәш бирсә дә, Каракош агач төбендәге чокырдан ни эшләп киңәш алсын? Бөтен халыкның Каракошның күзләре үткен дип мактаулары кая китә? Һәм Сукыр тычканның падишаһлар эшенә керешергә ни эше бар?

Ул, Сукыр тычкан берлә күп сөйләшмичә, ояны тиз генә ясарга кереште.

Озак та үтмәде, падишаһның сарае эшләнеп бетте. Бара торгач, балалар да булды, бәхет өстенә бәхет!

Берзаман Каракош иртә берлән, хатын вә балаларына азык алып шатланып кайтса, ни күзе берлән күрсен: имән ауган, һәм падишаһ хатыны вә шаһзадәләр барчасы басылып үлгәннәр.

Бу эштән падишаһ кошның йөрәге янып, үз-үзен бу рәвештә шелтәли башлады: «Мин бу бәлане һичнәрсәдән түгел, тик үземнең тәкәбберлегемнән генә күрәмен. Мин бик хур күргән Сукыр тычкан миңа ана нәсыйхәте кеби яхшы үгет бирде. Мин исә, нәфесемә ияреп, кабул итмәдем».

Шул арада бер яктан Сукыр тычкан да: «И падишаһ кош! Үзеңә мәгълүм: минем оям һәрвакытта да агач төбендә була, шул сәбәпле мин тамырлар хәлен бик яхшы беләм», – дип, Каракошның җәрәхәтенә тоз сипте.

## МӘЧЕ БАЛАСЫ ҺӘМ СЫЕРЧЫК

Кайсыдыр бер өйдә бер Сыерчык бар иде. Үзе сайрау һөнәрендә начар булса да, бик гакыллы вә бик фикерле булганлыктан, сайравының начарлыгын яшерә аладыр иде.

Шул ук өйдә бер Мәче баласы да булып, Сыерчык моның илә араларына кыл да сыймаслык дәрәҗәдә дус иде.

Мәче баласы да, бик юаш булганлыктан, Сыерчыкка сөемле иде. Бервакыт боларның хуҗалары кунаккамы, кайдадыр китеп бик озак торгач, Мәче баласы һәр көн барып ризыклана торган ашъяулыктан аерылып, монда ачлык, кыйхытлык[1] йөдәтә башлады.

Мәче баласы, рузаның[2] катылыгы үзәгенә үткәнлектән, идән буенда кызганыч тавышлар илә мыраулап, күңелсезләнеп йөри иде.

Бу хәлне күреп торгач, Сыерчык Мәче баласына киңәш юлында шушы рәвешчә сүзгә кереште:

– И дустым Песи! Син бигрәк саф күңелле вә юаш табигатьле икәнсең, мин синең үз файдаңны үзең белмәвеңә исем китә. Әнә борын астындук читлектә Тургай асылынып тора. Читлек ишеген ач та шул Тургайны алып аша. Син гафил булма, сиңа балалыгыңны ташларга вакыт инде. Бу дөньяда кем көчле булса, ул ни кыйлса да ирекле.

Фәйләсүф[3] Сыерчыкның бу сүзләре Мәче баласының хушына китеп[1], ул, дәрхаль читлекне ачып, Тургайны чыгарып, тотып ашады.

Бу Тургай, гәрчә Мәчене туйдырырлык булмаса да, йөрәк ялгарга ярады.

Соңра Мәче баласы, бөтенләй туюның да юлын эзләп, як-якка карады да, озак уйламыйча, теге киңәшне өйрәткән хәлфә Сыерчыкның үзен дә тәгъзим берлә генә[2] ашады.

*

Берәү кардәшенә кое казыса, үзе төшәр.

**ТАШБАКА ИЛӘ КУЯН**

Ташбака илә Куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.

Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.

Куян берзаман йокысыннан уянып караса, Ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән!

Инде безнең Куян артка калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?

## АРЫСЛАН ИЛӘ ТЫЧКАН

Тычкан, Арыслан янына килеп, тәгъзим берлә генә шул якын-тирәдә бер агач төбенә ояларга рөхсәт сорады вә диде: «И падишаһ! Син гәрчә урманда иң көчле вә гайрәтле бер зат булсаң да, гәрчә синең бер нәгъръң[1] бөтен җанварларны тетрәтергә җитсә дә, киләчәкне белеп булмый бит. Кем белә? Бәлки, мин шушы кадәр зәгыйфь вә көчсез бер мәхлук булсам да, бервакыт сезгә бер файда тиерермен».

Арыслан, Тычканның бу сүзләренә гаять тә ачуланып: «Синме?! И кызганыч җанвар! Кит, югал хәзер күземнән! Тере вакытта тизрәк башыңны алып кач. Югыйсә мин сине дөньяга килмәгән шикелле итәрмен. Миңа, Арысланга, файдам тияр дигән була бит! Ах, әдәпсез нәрсә!» – дип, бик каты гайрәтләнде.

Тычкан, мискин, бар хәле белән, җан коткарыр өчен качып, күздән дә югалды.

Ләкин Арысланның бу тәкәбберлеге буш кына калмады.

Бервакыт ул, үзенә азык эзләргә чыкканда, ялгыш Аучының үләннәр арасына корган авына эләкте. Монда инде нәгъръләр, үкерүләр файда бирми.

Мискин Арыслан никадәр тартылса да, йолкынса да, Аучының табышы гына булып калды: аны шәһәргә алып кайтып, кешеләргә күрсәтер өчен, тимер читлеккә ябып куйдылар.

Арыслан читлек эчендә теге Тычканны исенә төшерде. Әгәр Тычканга шәфкать иткән булса, ул, ауның җепләрен кимереп өзеп, Арысланны бәладән коткара алачак иде.

*

Коега төкермә, бервакыт су эчәргә кирәк булыр, диләр.

## БӘТИ

Бер Сарык бәтие, балалыгы вә яшьлеге илә Бүре тиресен киеп, бакчага сәер итәргә[1] китте.

Бу, шул кыяфәте илә бакчага кереп, яшел чирәмнәрдән татымакчы булып, авызын түбән таба сузган гына иде, шулвакыт моны ерактан күргән этләр, Бүре дип белеп, барчасы бердән моның өстенә атылып, кайсы

муеныннан, кайсы биленнән вә кайсы ботыннан тешләп, бичараны аяктан да ектылар.

Мискин Бәтинең әҗәле җитмәгәненә каршы, бу хәлне көтүчеләр күреп, этләрне көч илә генә аерып алдылар.

Этләр тешенә эләкмәк уен түгел; бичара Бәти үлемнән котылгач, көчкә-көчкә генә өстерәлеп, сарыклар абзарына барып керә алды һәм гомер буе ыңгырашып, күңелсезләнеп йөрүчән вә ашаганы да сеңми торган зәгыйфь бер Сарык булып калды.

Әгәр дә Бәтинең башында гакылы булса, Бүре тиресен кию кайда, бәлки, Бүрегә охшауны уйларга да куркыр иде.

*

Явызларга тыштан гына булса да охшарга ярамый.

## БАЛАНЫҢ АТА-АНАСЫН СӨЮЕ

Ун яшьлек бала – Шәмсетдин, үз авылларында бер бай кешегә барып, үзенә хезмәт сорады.

Бай кеше моны хезмәткә алырга риза булды вә әйтте: «Ярар, мин сине хезмәткә алырмын, көтү көтәрсең һәм, әгәр син яхшы хезмәт итсәң, аена алты тәңкә бәһа куярмын».

Шәмсетдин моңар каршы: «Ярар, мин кулымнан килгән хезмәтне кызганмам, ләкин син минем айлык бәһамне һәр атна саен бүлеп бирерсең. Чөнки өебездә әткәем, авырып ятканлыктан, эшли алмый, шул сәбәптән һәр атна саен аңа ризыкланырлык акча алып кайтып бирәсем килә», – диде.

Бай кешегә сабый бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кылуы бик ошады. Ул Шәмсетдиннең сүзенә «баш өсте» дип разый булуы өстенә аның айлык бәһасен дә арттырды.

## ҺӘРКЕМ ЭШТӘ

Борһанетдин: «Мин бүген сабакка бармыйм; анда барганчы, кырларга чыгып уйнармын», – дип, басу капкасыннан йөгереп чыгып китте.

Борһанетдин кырда бер Атны күрде. Ул тиз генә Ат янына барды да: «Әйдә, Бахбай, икәү уйныйк, күңел ачыйк», – диде.

Ат: «Юк, җаным, минем уйнарга вакытым юк; минем сабан сөрәсем бар, Хуҗама хезмәт итеп, ризык табасым бар, син үзең генә уйнарсың», – дип җавап бирде.

Бала, моннан киткәч, Умарта кортын күрде. Ул, аның янына да барып:

«Әй, Умарта корты! Әйдә икәү уйныйк, күңел ачыйк», – диде.

Умарта корты да җавабында: «Юк шул, минем эшем бар, җәй көннәре тиз үтеп китә. Минем көзгә кадәр төрле чәчәкләрдән ашыгып-ашыгып бал җыеп каласым бар, үзең генә уйна», – диде.

Борһанетдин, аптырагач, бер Кош янына барып, аның үзе берлә уйнавын үтенде.

Кош та, Борһанетдиннең үтенечен кабул итмичә: «Юк, бала, минем уйнарга вакытым юк; кечкенә балаларыма ашатыр өчен чебен-черкиләр аулыйсым бар», – диде.

Болай да булмагач, Борһанетдин тирән уйга чумды да тиз генә мәктәпкә таба йөгерде.

## РОДНОЙ ЯЗЫК

О язык родной, певучий, о родительская речь!
Что ещё на свете знал я, что сумел я уберечь?

Колыбель мою качая, тихо-тихо пела мать,
Подрастая, сказки бабушки я начал понимать.

О язык мой, мы навечно неразлучные друзья,
С детства стала мне понятна радость и печаль твоя.

О язык мой, как сердечно я молился в первый раз:
«Боже, – я шептал, – помилуй мать, отца, помилуй нас».

## РОДНОЙ АУЛ

На горе был построен мой аул,
Под горою родник, он к аулу прильнул,
Вкус воды ключевой, этих мест красоту
Всем моим существом, всей душою люблю.

Здесь родился, и здесь свет глазам моим дан,
Здесь впервые читать довелось мне Коран,
Здесь узнал, как учил и как жил Мухаммед,
Как страдал наш пророк, претерпел сколько бед.

Не забыть никогда, что здесь видеть пришлось,

Как в забавах счастливое время неслось,
Как пред нами, когда старший брат мой и я
За сохой шли вдвоём, раскрывалась земля.

Где ни буду я впредь, и каких только дел
Совершить мне ни даст Богом данный удел,
Буду в памяти вечно хранить, как живой,
Образ родины детства, деревни родной.

**МАЛЫШ И МОТЫЛЁК**

Малыш:
Подожди, Мотылёк,
Ты так долго летал,
Расскажи, Мотылёк:
Разве ты не устал?

Где твой домик стоит –
Свет вокруг или тень?
Чем бываешь ты сыт?
Чем ты занят весь день?

Мотылёк:
На зелёной лужайке
Живу я, дружок,
Над лужайкой летаю
В погожий денёк –

Там, где нега и зной,
Где цветов аромат.
Этой сыт я едой,
Этой ласке я рад.

И как этот денёк,
Моя жизнь коротка...
Если ты мне дружок –
Не лови Мотылька!

**ФАТИМА И СОЛОВЕЙ**

Фатима:
Что ж не слышно твоих песен, Соловей?
На душе от них светлей и веселей.
Вдоволь корма в твоей клетке вижу я,
Что ж опущена головушка твоя?

Соловей:
Ах, я песни распевал в лесу родном.
До чего ж там было чудно всё кругом!
Как счастливым быть, как песни петь мне тут?
Три птенца меня в гнезде родимом ждут.

Ждёт меня моя любимая жена,
От разлуки убивается она.
Даже если золотая клетка, но
Клетка клеткой остаётся всё равно.

Фатима:
Я открыла клетку. Вылети – и ввысь.
На свободе за меня ты помолись.
И не жди. Лети в зелёный лес скорей
К милым деткам, к славной жёнушке своей!

**ЛАСТОЧКА**

Недавно ласточка, что сердцу так мила,
Там, над окном моим, гнездо себе вила.

Таскала глину в остром клювике своём,
Из глины строила она красивый дом.

Трудилась долго, возводя свой лёгкий кров,
А после вывела хорошеньких птенцов.

Чтобы сыта была вся птичья детвора,
Жучков и мошек мать приносит им с утра.

Пусть непогода на дворе и ночь темна,

Не шевельнётся в тёплом гнёздышке она,

Укроет голову тихонечко крылом
И сладко спит она, окутана теплом.

И что ей молния и гром, что шум людской!
Спит крепко ласточка, и дорог ей покой.

Чтоб ни случилось на земле, ей нет забот, –
Она и клювиком своим не поведёт.

**ОЗОРНОЙ КОТЁНОК**

Погляди, взялась за дело не на шутку Ламига,
Платье шьёт любимой кукле – знать, ей кукла дорога!

«Ну, готова ли обнова?» – лёжа, кукла платья ждёт,
Да и как не волноваться – скоро праздник к нам придёт!

А котёнок притаился, за катушкою следит,
Шевельнётся ли катушка, с нетерпением глядит.

Ох, сейчас котёнок прыгнет –
лишь мелькнёт пушистый бок!
И начнёт играть катушкой, нитки путая в клубок.

Нет заботы у котёнка: прыг да скок – и всё не лень!
Озорник, шалун весёлый – так и скачет целый день!

**РАБОТА**

Не жалей, малыш, стараний! Для работы создан день,
А устанешь – сон спокойный принесёт ночная тень.

Подымайся утром рано и берись за свой урок,
Срок бывает для работы, для игры бывает срок.

Видишь солнца труд упорный: поднимается с зарёй,
Целый день плывёт по небу, ярко светит день-деньской.

Лишь потом, устав как будто, покидает небосклон,
Отдыхает за горою и земле дарует сон.

Коль в труде примером станет солнце яркое тебе –
Сам, как солнце, засияешь на земле среди людей.

**КОНЧИЛ ДЕЛО – ГУЛЯЙ СМЕЛО!**

За окном сияет лето, за столом сидит Дитя
У окошка бокового, в книжке пальчиком водя.

За уроками прилежно, повторяя много раз,
Слово за слово читает и не сводит с книжки глаз.

Приглашает его Солнце: – Детка, выйди, погуляй,
Во дворе, в саду побегай, хватит, больше не читай.

Засиделся ты на месте и читаешь ты давно,
Погляди, как здесь привольно, посмотри на двор в окно.

Говорит Дитя на это Солнцу встречные слова:
– Должен выучить уроки я как следует сперва.

Поиграть всегда успею, как доделаю дела,
А до той поры не встану ни за что из-за стола.

На занятия и отдых сам себе назначил срок,
Со вниманьем неослабным продолжает он урок.

Засвистел, запел на ветке в это время Соловей,
Он свистит-поёт о том же: – Выходи гулять скорей!

Засиделся ты на месте и читаешь ты давно,
Погляди, как здесь привольно, посмотри на двор в окно.

Соловью в ответ Ребёнок говорит свои слова:
– Должен выучить уроки я как следует сперва.

Не зови из дому свистом ты, Соловушка, меня,
Вот доделаю уроки, выйду я и без тебя.

На гулянье и уроки сам себе поставил срок,
С интересом и вниманьем продолжает он урок.

